**Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында гражданнар җыены**

**К А Р А Р**

27 ноябрь 2025 ел № 1

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районының Абалач авыл
җирлегенең Абалач авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Уставының 22 ст., Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләре буенча гражданнар җыены уздыру турында" 2025 елның 17 ноябрендәге 1 нче номерлы карары нигезендә 2025 елның 27 ноябрендә узган гражданнар җыенында "2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1-2 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм аларга тиңләштерелгәннәрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затларны түләүдән азат итәргә, ә күпбалалаы гаиләләргә түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?" дигән сорау каралды һәм йомгаклау беркетмәсе төзелде.

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(юлларны кардан чистарту, узган еллардан калган үзара салым акчаларын юлларны кардан чистарга юнәлтергә).

2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторына роторлы чапкыч сатып алу, үлән чабу, Абалач авылында мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру – 1 данә, балалар мәйданчыгында яктырту

җайланмалары, балалар уен мәйданчыгы өчен кече архитектура формалары сатып алу һәм урнаштыру, суга батыру насосы сатып алу – 2 данә.

3. Ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратны төзекләндерү - агачларны кисү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 198 граждан кертелде, тавыш бирүдә катнашучылар саны 104 кеше.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 104 катнашучы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1.Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2026 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә. 1-2 нче төркем инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм аларга тиңләштерелгәннәрне, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, көндезге уку формасында укучы студентларны, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затларны түләүдән азат итәргә, ә күпбалалаы гаиләләргә түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә һәм үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә Сез ризамы?” дигән сорау каралган һәм карар кабул ителгән дип санарга

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;(юлларны кардан чистарту, узган еллардан калган үзара салым акчаларын юлларны кардан чистарга юнәлтергә).

2. Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (МТЗ-82 тракторына роторлы чапкыч сатып алу, үлән чабу, Абалач авылында мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру – 1 данә, балалар мәйданчыгында яктырту җайланмалары, балалар уен мәйданчыгы өчен кече архитектура формалары сатып алу һәм урнаштыру, суга батыру насосы сатып алу – 2 данә.

3. Ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (зиратны төзекләндерү - агачларны кисү).

3. Әлеге карарны Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Абалач авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге башлыгы И.Н. Әкбәров